**Э.Х. Кадирова**
*г. Казань*

# КОСМОНИМЫ В ТЮРКО-ТАТАРСКИХ ПИСЬМЕННЫХ ПАМЯТНИКАХ (ТӨРКИ-ТАТАР ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРДӘ КОСМОНИМНАР)

Аннотация. В данной статье рассмтриваются космонимы в тюрко-татарских письменных памятниках.

Элекке заманнардан ук күк җисемнәренә аерым исемнәр биргәннәр. Төрле язма истәлекләрдә бу борынгы терминология еш очрый. Борынгы төрки сүзлектә күк җисемнәренең санскриттан килгән атамалары да урын алган. Авторлар аларны рун язулары белән язылган магик эчтәлекле кульязмалардан китерәләр: aditja soma anaraq bud braxsvati ŝűkŭr ŝaničar jeti graxlar ‘Солнце, Луна, Марс, Меркурий, Юпитер, Венера, Сатурн – семь планет’ [5: 10]. XI гасырга караган «Котадгу белек» (Й.Баласагуни) поэмасында галәм төзелешенә багышланган аерым бүлек бар:

Буларда иң өстүн Сәкәнтир (Сатурн) йурыр
Эки йил сэкиз ай бир эвдә калыр
аныңда баса болды эккинч Оңай (Юпитер)
Бир эвдә калыр он адын экки ай
Үчүнчи Көрүд (Марс) кэлди көксүн йурыр
Кайука бу бакса йашармыш курыр.

Автор билгеләвенчә, күкнең җиде сферасын җиде планета төзи һәм алар Җиргә ераклыклары буенча түбәндәге тәртиптә урнашкан: Ай, Меркурий, Венера, Кояш, Марс, Юпитер, Сатурн [1: 40]. Шушы ук әсәрдә йолдызлыкларның исемнәре бирелә: eräntaz ‘игезәкләр’ [5: 485], qyčiq ‘рак’ [5: 463], arslan ‘арслан’ [5: 132], baliq ‘балык’ [5: 126], särätan ‘рак’ [5: 493], konak ‘сукояр’ [5: 322], čaбan, čadan ‘чаян’[5: 135,136], qozi ‘кучкар’[5: 126] h.б. Күп кенә төрки язма истәлекләрнең башында Аллаһы тәгаләнең берлеге, шуннан галәм җисемнәре турында язу гадәткә кергән булган. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында да беренче баб кыскача шулай башланып китә. Котб, гомумән, сәнгатьчә тасвирлау чарасы буларак та күк җисемнәре исемнәренә еш мөрәҗәгать итә.

Безгә иң якын йолдыз – Кояш. Бу йолдызны белдерү өчен Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында борынгы төрки телдә үк теркәлгән [5: 327] көн, көнәш һәм кояш вариантлары бик еш һәм күп очракта геройның гүзәллеген бирү өчен кулланыла:

Җәмалең куйаш кеби, гыйшкың кати [7: 160];

Биңзе нуры көнәш кеби балкыр имди [7: 134];

Бу угъланның биңзе нурлу дуар күндән [7: 176].

Алтын Урда чоры авторлары да чагыштырулар составында кояшны яратып файдаланалар: Күреп көн тиг йөзен хәйранга калды [3: 60]. Соңгырак чорда Мөхәммәдьяр, Мәүлә Колый иҗатларында мондый мисаллар шактый:

Көн йөзендин ай, койаш булгай хәҗил,

Ләбләрендин кыз Мисри мөнфәгыйл (52 б: 4 Т.м.).

Мәүлә Колый хикмәтләрендә галимнәрне дә кояш белән тиңли: Галимләр күк йөзендә көнәш йәңлигъ,

Шәкердләр тулыб торган айга йәңлигъ (34: 5).

Шуңа охшаш чагыштыруны Г. Утыз Имәнидә дә күрәбез:

Тагаллемдин улурсән сәхибе садыр,

Көнәшдиндер һилалның улмасы бәдер.

Матур әдәбиятта Кояш белән янәшә һәрвакыт Ай сүзе куела. Мәгълүм булганча, ай (ярым ай) мөселман динен кабул иткәнче үк төркиләр өчен изге саналган. Яңа дингә күчкәч тә алар кабер ташларына Ай капкасын куйганнар. Җиргә карата һәм үзен яктыртучы Кояшка карата төрлечә торышта булуыннан айның рәвеше үзгәрә. Ай тар һәм киң урак рәвешендә шулай ук башка рәвешләрдә булырга мөмкин. Нинди торышта булуына карап, аның исеме дә төрле. Һилял, яңа айны аңлатып, әсәрләрдә геройның кашларын сурәтләү өчен килә: Һиляла биңзәр сәнең кашларың бар [6: 162]; Һилялә охшар сәнең кашларың бар [7:109], камәр сүзе «матур»ның битенең түгәрәклеген, тулылыгын күрсәтә: Аны сән җөмлә шагыйрь кәмтәре бел, Камәр йөзгә һәмишә Мөштәри бел (Сөхәйл вә Гөлдерсен).

Алтын Урда чоры язма истәлекләрендә чибәр кызга маһ дип эндәшү булган: Көңүлләр ахыдын иймәнгил, әй маһ (Мәхәббәтнамә) [14: 217).

Кояш белән Айдан соң якты яктырткычларның берсе – Чулпан йолдызы. Матур әдәбият әсәрләрендә, мәкаль-әйтемнәрдә, хәтта төрле йолаларга караган мифларда бу йолдыз искә алына. Борынгы язма истәлекләрдә ул Sevit, Zoqra [10: 443], Soqra [10: 442] формаларында очрый. Шулай ук кайбер сүзлекләрдә, мәсәлән, XIV гасыр истәлеге «Әт-төхфә» дә Чолпан варианты да теркәлгән [16: 410]. Хәзерге көндә күп төрки халыкларда кулланылучы (каз. Шолпан, уйг. чолбан, төрк. Чолпан) бу сүзнең килеп чыгышын чабан сүзе белән, ягъни көтүче йолдызы дип аңлаталар [12: 234). Әмма Чолпан варианты бары тик сүзлекләрдә генә очрый, ә матур әдәбиятта Зөһрә сүзе бирелә. Ул, алда

санап үтелгән космонимнар кебек үк, геройның гүзәллеген тасвирлау өчен еш кулланыла: Аның тик чәң орырга кемдә зәһрә, Оялыр ирде андин күктә Зөһрә [3: 130]. Бу чор язма истәлекләрендә Зөһрә антропоним булып та хезмәт итә: Бер көн бер хатын килде хәлвәттә. Зөһрә атлыг, инкән сәхипҗәмал әрди [13: 307). Мисаллардан күренгәнчә, Зөһрәнең матурлыгына еш кына Юпитер соклана. Кояш системасының иң зур планетасы Юпитер истәлекләрдә Мөштәри исемен йөртә [3: 148, 198]. Матур әдәбият стилендә башка планеталар да гарәп алынмалары белән белдереләләр: Гутарид ‘Меркурий’, Зохул ‘Сатурн’, Маррих ‘Марс’: [14: 244].

Плеядалар исемле йолдыз төркеме хәзер халык телендә Иләк йолдыз дип йөртелә. Элекке язма әдәбиятта ул Өлкәр дип кулланыла [4: 625; 6: 213; 15: 241; 455). Бу сүзнең килеп чыгышын өлкән сүзе белән бәйлиләр [9: 383]. Татар халкының фольклорында космонимнарны күзәткән В.М.Беркутов өлкәр сүзе кергән бик эчтәлекле татар мәкаль-әйтемнәрен китерә: Өлкәр батты, Жир катты; Өлкәр җиргә төшкәндә сыер суга төшә [2: 28]. Матур әдәбиятта аның гарәпчәсе Сүраййа дә файдаланылган [14: 278; 15: 307).

XIV гасыр язма ядкәрләрендә йолдызлык мәгънәсендә борынгы төрки телдә үк кулланылган бурж, бурҗис сүзләре еш очрый [14: 280; 279; 3: 72]: Йүзүң кашың куйаш ай бурҗы ечрә (Мәхәббәтнамә) ‘твое лицо, брови – солнце и луна в окружении планет’; Балык бурҗындин ай кем баш көтүрде, Бу шаһлык бурҗында шаһны көтүрде (Хөсрәү вә Ширин). Мисаллар бу сүзнең дә шагыйрьләр тарафыннан чагыштырулар төзүдә файдаланылганын күрсәтә.

Җидегән йолдыз борынгы заманнардан ук төрки әдәбиятта jetigän вариантында теркәлеп калган [5: 487]. Шул ук формада ул «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында очрый [15: 249). Бу сүзнең килеп чыгышы ачык, ягъни йолдызлыкта җиде якты йолдыз булганлыктан җиде (jeti) саны сүзнең нигезендә ята [11: 375].

Борынгы сүзлекләрдә космонимнар шулай ук урын алган: Тӓмир казук, Сибӓк ‘Казык йолдыз’ [16: 65], Ак айгыр ‘Сириус’ [16: 65], Арык так ‘Игезәкләр йолдызлыгы’ [16: 65). Ә XVI гасыр гарәпчә - төрки-татарча сүзлектә Гутарид (Меркурий) - өченче күктәге йолдыз, Муштәри (Юпитер) – алтынчы күктәге, ә Маррих (Марс) – дүртенче күктәге йолдыз, Зөһрә – бер йолдыз, Зоһул – бер йылдыргы дип тәрҗемә ителгән. XVI гасыр Коръән тәфсирендә йолдызлар турында шулай ук мәгълүмат бар: Йиде йылдуз анлар: бере – Көн, бере – Ай, бере – Зухал, бере – Мөштәри, бере – Миранҗ, бере – Гутарид, бере – Зөһрә (763).

Димәк, язма истәлекләрдә күк җисемнәренең исемнәре еш кулланыла. Аларның кайберләре мифологиягә бәйле рәвештә файдаланыла. Мәсәлән, Мәррих ‘Марс’ «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында күктән Мәликәнең башкаларны тар-мар итүенә шатлана [3: 46]. Космонимнар поэзиядә, әсәргә куелган «таләпләр»гә туры китереп, керештә, яки геройны сурәтләгәндә охшату-чагыштыруларда бирелә. Матур әдәбиятта күк жисемнәренең, бигрәк тә планеталарның бары тик гарәпчә исемнәре генә кулланыла.

**Әдәбият**


1. Баласагунский Ю. Благодатное знание. – Москва: Наука, 1983, 557 с.
2. Беркутов В.М. Народный календарь и метрология булгаро-татар. – Казань, 1987. – 95 с.
3. Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1981. – 246 б.
4. Воронцов-Вельяминов Б.А. Астрономия: Урта мәкт. 11 кл. өчен дәреслек. – Казан: Тат. кит. нәшр.,1992. – 192 б.
5. Древнетюркский словарь. – Л.: Наука, 1969. – 676 с.
6. Кандалый Г. Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. – 558 б.
7. Кол Гали. Кыйссаи Йусуф. – Казань, 1985. – 540 б.
8. Курышжанов А.К. Исследование по лексике старокыпчакского письменного памятника XIII в. “Тюркско-арабского словаря”. – Алма-Ата, 1970. – 234 с.
9. Максютова Н. Башкирская космонимия // Ономастика Поволжья. – Уфа, 1973. – С. 382-384.
10. Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности. Тексты и исследования. – М.-Л., 1951. – 451 с.
11. Никонов В.А. Космонимия Поволжья // Ономастика Поволжья. – Уфа, 1973. – С. 373-381.
12. Нуржанова Д.К. Казахская космонимия // Этнография имен. – М.: Наука. – С. 234–236.
13. Нуриева Ф.Ш. Махмуд Болгари "Нахдж ал-Фарадис . – Казан: Тат. кит нәшр., 2001. – 358 б.
14. Фазылов Э.И. Староузбекский язык. Хорезмийские памятники XIV в. – Т. I. – Ташкент: Фан, 1966. – 650 с.
15. Фазылов Э.И. Староузбекский язык. Хорезмийские памятники XIV в. – Т. II. – Ташкент: Фан,1971. – 779 с.
16. Изысканный дар тюркскому языку. – Ташкент, 1978. – 450 с.